ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» 141-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, А.В. Ляпунов, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» 141-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 493-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев,
А.В. Ляпунов,
Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өчен шартлар тудыру максатларында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар арасында мөнәсәбәтләрне җайга сала, эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектының хокукый статусын һәм бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендәге ярдәм чараларын билгели.

2 статья. **Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән законнары һәм норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:
1) бизнесны җаваплы алып бару – Татарстан Республикасының тотрыклы социаль-икътисадый үсешенә ярдәм итә торган, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау, файдалана алырлык иң яхшы технологияләрне куллану, хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары өчен өстәмә социаль гарантияләр билгеләү, экологик, социаль проектларны, белем бирү, хәйрия проектларын һәм Татарстан Республикасы халкының яшәү дәрәҗәсен күтәрүгә бәйле башка проектларны гамәлгә ашыру юлы белән, юридик затның яисә индивидуаль эшкуарның эшчәнлеге;
2) эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты – бизнесны җаваплы алып баруны гамәлгә ашыручы һәм әлеге Закон нигезендә билгеләнгән критерийларга туры килүче юридик зат яисә индивидуаль эшкуар.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

4 статья. **Бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өчен шартлар тудыру;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендәге вәкаләтле органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләү;

3) юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларына кертү критерийларын билгеләү;

4) эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусын бирү, озайту, туктату тәртибен һәм аны туктату нигезләрен билгеләү, шулай ук эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусының гамәлдә булу срогын билгеләү;

5) Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрын (алга таба шулай ук – Реестр) төзү һәм алып бару тәртибен, шул исәптән Реестрдан өземтә бирү тәртибен, билгеләү, шулай ук Реестрдагы белешмәләр составын билгеләү;

6) бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме чаралары биргәндә республика башкарма хакимият органнары һәм эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары хезмәттәшлеге регламентын раслау;

7) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендәге вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусын бирү;

2) Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрын булдыру һәм аны алып бару;

3) Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү торышына, шулай ук бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә хокуктан файдалануга мониторинг ясау;

4) бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә республика башкарма хакимияте органнары эшчәнлеген, шул исәптән дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә, координацияләү, методик һәм методологик ярдәм күрсәтү;

5) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусы**

1. Эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларына кертеп карау критерийларына ярашлы рәвештә юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга бирелә.

2. Юридик затны һәм индивидуаль эшкуарны эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларына кертеп карау критерийларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан үзгәртелүе элек бирелгән эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусын бетерү өчен нигез булмый.

6 статья. **Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестры**

1. Эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусы бирелгән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар турында белешмәләр Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрына кертелә.

2. Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрын төзү һәм алып бару вәкаләтле орган тарафыннан турыдан-туры яисә аның ведомство карамагындагы дәүләт учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрындагы белешмәләр вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

7 статья. **Бизнесны җаваплы алып бару өлкәсендә дәүләт ярдәме чаралары**

1. Бизнесны җаваплы алып баруны үстерүгә кызыксындыру максатларында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларына Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт ярдәме чаралары күрсәтелергә мөмкин.

2. Реестрга кертелгән эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларына бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан күрсәтелә.

3. Бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме оештыру, мәгълүмат, консультация, мөлкәт һәм финанс ярдәме күрсәтү юлы белән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка рәвешләрдә күрсәтелергә мөмкин.

4. Эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусы бетерелгән очракта әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәмен күрсәтү туктатыла.

8 статья. **Бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә ярдәм чараларын җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтү**

Җирле үзидарә органнары бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә ярдәмне Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә күрсәтә.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) бизнесны җаваплы алып бару системасын кертү юлы белән Татарстан Республикасының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү өчен шартлар булдыру максатларында эшләнде.

Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгының 2023 елның 29 декабрендәге 1765-статья номерлы боерыгы белән «ГОСТ Р 71198-2023. Россия Федерациясе илкүләм стандарты. Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының эшлекле абруе индексы (ЭКГ-рейтинг). Җаваплы бизнесны бәяләү методикасы һәм аның ЭКГ-рейтингын төзү тәртибе» расланган һәм гамәлгә кертелгән.

Илкүләм стандарт эшкуарлык эшчәнлеге субъектларын бәяләүнең аларның социаль-икътисадый һәм экологик җаваплылыгын комплекслы билгеләүгә юнәлдерелгән методикасын, шулай ук эшлекле абруй индексын (ЭКГ-рейтингны) уздырылган бәяләүгә нигезләнеп төзү тәртибен билгели.

Илкүләм стандарт нигезләмәләре икътисадый сәясәт нәтиҗәлелеген арттыру, контроль чараларын планлаштыру һәм, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының милли максатларга ирешү керткән өлешенә мониторингны исәпкә алып, дәүләт ярдәме чараларын кору өчен кертелгән.

Закон проекты Илкүләм стандарт нигезендә Татарстан Республикасында бизнесны үстерү өчен норматив хокукый база булдыруга юнәлтелгән.

Бу максатларда закон проектында «бизнесны җаваплы алып бару» һәм «эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты» төшенчәләрен кертү, бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләрен бүлү, шулай ук бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме чараларын билгеләү тәкъдим ителә.

Закон проекты 2015 елда БМО Генераль Ассамблеясы тарафыннан кабул ителгән дәүләтләр икътисадын тотрыклы үстерү максатларына тулысынча туры килә һәм бизнесны җаваплы алып баруга карата социаль гаделлек һәм экологик җаваплылык принципларына нигезләнгән комплекслы якын килүне гамәлгә ашыра.

**«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:

юридик затны һәм индивидуаль эшкуарны эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларына кертеп карау критерийларын;

эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусын бирү, озайту, бетерү тәртибен һәм мондый статусны бетерү өчен нигезләрен, шулай ук эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусының гамәлдә булу срогын;

Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрын төзү тәртибен, шул исәптән Реестрдан өземтәләр бирү тәртибен, шулай ук Реестрдагы белешмәләр составын;

бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә республика башкарма хакимияте органнарының һәм эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын.

**«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.